бу тәнкыйтен аннан соң да еш искә төшерә, үзенә шәфкать һәм ихлас юлын күрсәткәне өчен аңа рәхмәт укый. Шулай итеп, Бәязид, гәрчә бу кадәр ачы һәм ачулы сүзләргә лаек булмаса да, аларны үзе өчен файдалы санаган, үзен камилләштерү турында уйланган.

Бу кыйссадан гыйбрәт шулдыр: ачы хакыйкатьне сөйләгән дустыңа каршы килергә ашыкма, тәнкыйтьтән нәтиҗә ясап, үзеңне төзәтергә тырыш.

("Дин вә йола" газетасыннан)

Ялган сөйләү мөмкин булган вакытлар

Бел ки, ялган сөйләү хәрәм. Чөнки ул калебкә начар тәэсир итә һәм аны каралта. Әмма кайвакытта хәерле ният белән ялган сөйләргә ярый, чөнки хәерле ният белән ялган сөйләгәндә калеб каралмый. Мәсәлән, залимнән котылу өчен ялган сөйләү мөмкин. Бу вакыт ялган сөйләү мөмкин генә түгел, хәтта фарыз да. Пәйгамбәребез өч очракта ялган сөйләүгә рөхсәт биргән: сугыш вакытында планны дошманга сөйләмәс өчен; ике кеше арасын яхшырту өчен; ике хатынлы кешегә һәрберсенең күңелен күрү өчен сине күбрәк яратам, дип әйтү. Бер залим бер кешенең малын тартып алырга теләсә, ул үз малының кайда икәнен әйтмәскә тиеш, бәлки, белмим, дип әйтергә тиеш.

Шулай ук берәүнең кылган гөнаһы турында сорасалар да, ул сөйләргә тиеш түгел. Чөнки шәригать яман эшләрне яшерергә куша. Бел ки, берәүнең хакыйкатьтә белмәгән риваятьне сөйләве яки белмәгән сорауга җавап бирүе - хәрәм гамәл. Уйлап чыгарып хәдисләр сөйләү дә хәрәм. Пәйгамбәребез әйтте: *«Мин сөйләмәгән сүзләрне миңа иснад иткән кеше җәһәннәмдә үзенә урын хәзерләнгән дип белсен»*. Шулай ук ялган сөйләмәү өчен анык булмаган җавап бирергә ярый. Риваять ителгән: Мөтәрриф хәзрәтләре әмир янына килгәч, әмир: ни өчен безнең яныбызга сирәк киләсең, диде. Мөтәрриф, әмир янына киткәннән бирле, Аллаһының рөхсәте булмыйча, урынымнан торганым булмады, диде. Әмир ул хаста яткан, дип уйлады. Мөтәрриф тә ялганламады. Чөнки Аллаһының рөхсәтеннән башка беркем дә урынынан тора алмый, әлбәттә. Беркөнне Мөгаз хәзрәти Гомәр кушкан эшне бетереп өенә кайткач, хатыны, бу кадәр зәкәт җыйдың, безгә берәр нәрсә алып кайттыңмы дип сорады. Минем янымда бер күзәтүче бар иде, мин бернәрсә дә алып кайта алмадым, диде ул. Ягъни мине Аллаһы Тәгалә күзәтеп тора, димәкче иде. Әмма хатыны Гомәр аның иренең өстеннән бер күзәтүче җибәргән дип зан итте. Һәм шунда ук Гомәр янына китте. Һәм: «Йә мөәминнәр әмире, Мөгаз Рәсүлуллаһ һәм Әбу Бәкер вакытында ышанычлы иде, ә син аңа күзәтүче билгеләгәнсең икән», – диде. Гомәр бу сүзгә үпкәләп, Мөгазне чакырып хәлне сөйләп бирде. Мөгаз Аллаһы Тәгалә турында әйткәнен сөйләгәч, Гомәр көлемсерәде һәм Мөгазнең хатынына бүләк җибәрде. Бел ки, мондый хәйлә ихтыяҗ булганда гына җаиз була.

Хөҗҗәтүл-Исләм имам
МӨХӘММӘД ӘЛ-ГАЗАЛИ.

("Мөселман календаре"ннан)

Исламда дәва

Барлык галәмнәрне юктан бар кылучы, барлык мәхлукларын тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә салаватларыбыз булса иде. Коръән-Кәримдә кешенең тәненә, рухына олуг әһәмият-игътибар бирелә. Хәрәм-хәләлнең аңлатмалары ризыкта, эчемлектә булсынмы, төрле мөгамәләләрдә булсынмы, хассатан шифа-дәва белән бәйле аятьләр иңдерде. Мәсәлән, бер аятендә Аллаһы Тәгалә: *«Вә иңдердек Без Коръәндә сезгә шифа бирә торган вә рәхмәткә ирештерә торган аятьләрне»,* – дип әйтә. Икенче аятикәримәдә: *«Әгәр дә син чирләсәң, ул Коръән – сиңа шифа бирүчедер»,* дип бәян итә.

Тыйбб гыйлеме белән кызыксынучылар Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең кеше дәвалауга күп киңәшләрен вә хәдисләрен калдырганнарын күрер. Бу хәдисләрен Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзеннән уйлап чыгармаган, ә алар Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән. Хак Тәгалә әйтә: *«Пәйгамбәр үзеннән берни дә сөйләми. Бәлки, һәр сүзендә аның Бездән килгән вәхидер».*

Кешене еш кына догалар, ягъни өшкерү ярдәмендә дәвалыйлар. Өшкерүләрнең файдасы булсын өчен, өшкерә торган кешенең яхшы, изге, тәкъва булуы кирәк, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтә: *«Хакыйкатьтә, Ходаегыз тәкъва булган кешеләрнең догаларын кабул итәр».* Өшкерүнең шартларыннан: өшкергәндә Аллаһы Тәгалә исеменнән башка өшкермәскә вә яман ният белән кылмаска. Өшкергән догаларына шикләнмәү, аның шифасына тулысынча ышану.

("Мөселман календаре"ннан)

Күркәм холык турында

Йөрәкне төзәтү өчен аны кабахәт холыклардан һәм сыйфатлардан чистартырга, мактаулы сыйфатлар белән бизәргә кирәк. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Аллаһы Тәгалә каршында начар холыктан да яманрак нәрсә юк. Бу явыз холыкның иясе һич гөнаһтан чыкмас, чыкса да, икенче гөнаһка гына төшәр».*

Гайшә радыйаллаһу ганһәдән риваять ителә: «Пәйгамбәр: *«Һәрбер гөнаһка, тәүбә итсәң, тәүбә буладыр. Ләкин начар холыклы кешегә тәүбә юк, чөнки ул гөнаһыннан тәүбә итми. Тәүбә итсә дә, әлек кылган гөнаһыннан явызрак гөнаһка кире кайта»,* – дип әйткән».

Габбасның улыннан риваять кылына: «Пәйгамбәр: *«Су бозны юкка чыгарган кебек, күркәм холыклар да гөнаһларны юкка чыгара. Серкә (уксус) балны бозган кебек, начар холыклар да гамәлләрне бозалар»,* – дигән».

Әнәстән риваять кылына: «Пәйгамбәр: *«Дөреслектә, кеше күркәм холкы белән ахирәтнең бөек дәрәҗәләренә ирешер, хәтта аның гыйбадәте зәгыйфь булса да. Бәндә явызлыгы сәбәпле җәһәннәмнең иң түбән дәрәҗәсенә төшәр, хәтта гыйбадәте күп булса да»,* – дип әйткән».

Әбу һүрайра радыйаллаһу ганһедән риваять ителә: «Мин Пәйгамбәрнең: *«Пәйгамбәр итеп Аллаһы Тәгалә тарафыннан күркәм холыкларны тәмам кылыр өчен (ягъни аңлатыр өчен) җибәрелдем»,* – дигәнен ишеттем». Әбу һүрайра радыйаллаһу ганһе тапшырган тагын бер хәдис: «Пәйгамбәр миңа: *«Әй, Әбу һүрайра, син күркәм холыклы булырга тиеш»,* – диде. Мин: «Нәрсә ул күркәм холык?» – дип сорадым. Ул: *«Сине дошман күргән кешене дус күрү, сиңа золымлык кылган кешене гафу итү, сине нәрсәдән булса да мәхрүм кылган кешегә шул нәрсәне бирү»,* – дип җавап бирде».

("Дин вә йола" газетасыннан)

Көнчелек

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдис-шәрифендә: *«Көнчелек яхшылыкларны нәкъ ут коры утынны ашаган шикелле ашап барыр»,* – дигән. Шулай Рәсүлуллаһ иман әһелләренә көнчелекнең нәрсә икәнлеген ачыклап бирде. Мөселманнарга карап: *«Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегез белән араны өзмәгез, бер-берегезне күрмәс булмагыз, бер-берегезгә дошман булмагыз, Аллаһы бәндәләре буларак, бер-берегезгә кардәш булыгыз!»* – дип киңәш-нәсыйхәт бирә.

Шушы хәдис-шәрифтәге тыюларга күз салсак, «бер-берегездән көнләшмәгез» дию тикмәгә генә беренче урында тормас. Бер-береңә дошман булу да, бер-берең белән араларны өзү дә, бер-береңне күрмәс-сөймәс булу да - барысы да көнләшү белән бәйле, барысының да асылы, нигезе шул көнчелек белән тоташкан. Элек тә, бүген дә бөтен бәла-казалар, хәсрәтләр, сугышлар, дошманлашулар, бер туганның икенче туганга пычак күтәрүе шул көнләшү дигән нәрсә белән, хәсетлек белән бәйле булып кала. «Үзегезгә элегрәк булган өммәтләрнең авыруы әләкте: көнчелек һәм күралмаучылык. Бер-береңне күралмау, нәфрәтләну – пәке белән бердер. Бу очракта сүз чәч кыра торган пәке түгел, динне кыра торган пәке турындадыр. Җаным Аның хөкемендә булучы Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, иман китермичә, җәннәткә кермәссез, бер-берегезне якын күрмичә, яратмыйча, иман да китерә алмассыз. Сезгә шуны раслый торган нәрсәнең ни икәнлеген ачыйммы? Бер-берегезгә сәлам әйтегез, сәламләү таратыгыз». Икенче бер хәдисендә Рәсүл Әгъзам: *«Алдагы өммәтләрнең авыруы сезгә дә тиячәк»,* – дигән. Шуннан соң янындагы халык: «Йә, Рәсүлуллаһ! Нинди авыру турында сүз бара?» – дип аптырый. Рәсүлуллаһ: *«Тәкәбберлек, масаю, дөньялык өчен мал арттыру, бер-берең белән узышу, бер-береңнән ераклашу, бер-береңнән көнләшү авыруы. Шундый дәрәҗәгә җитәр ки, хәтта башта бозыклык, аннан соң бер-береңне кыру китәр»,* – дип, Рәсүлуллаһ бу хәдистә дә авыруларның кайсысы кыруга, фетнәгә, үтерешкә китереп чыгарачак икәнлеген күрсәтә.

Янә сүз көнчелек, хәсетләнү турында бара. Коръәнгә күз салыгыз әле! Иблис атабыз Адәм, анабыз Һавага бирелгән дәрәҗәдән көнләште. Нәтиҗәдә, адәм угыллары җәннәткә бик олы сынаулар үтеп кенә, Аллаһы Тәгаләнең илаһи рәхмәте белән генә кире кайтырлар. Барысы да түгел, анысын да онытмыйк! Шуннан Кабил белән Һабил, Адәм атабызның угыллары, көнләшеп, бер туган икенче кан туганын үтереп ташлады. Зәкәрия пәйгамбәр: *«Аллаһы Тәгалә: «Көнче – Минем нигъмәтемнең дошманы, тәкъдире белән тарткалашучы, ачуымны чыгаручы, бәндәләремә чыгарган ризык өлеше белән риза булмаучы»,* – дип әйтте», – дигән. Әйе, кеше башка кешенең малыннан, кыяфәтеннән, дәрәҗәсеннән, өстенлегеннән көнләшсә – Аллаһы Тәгаләнең дошманы булыр. Ни өчен? һәркемгә ризыкны, дәрәҗәне, саулыкны, кыяфәтне бирүче Аллаһы Тәгалә бер Үзе генә. Димәк, берәүнең саулыгына «авырмый, чирләми, гомере буена сау-сәламәт» дип әйтүләрне исегезгә төшерегез! Икенче бер бәндә көнләшсә, көнче Аллаһы Тәгалә белән тарткалаша булып чыга. Ул кеше саулыкны кайдандыр үзе сатып алмаган бит! Ул саулыкны аңа Ходай Тәгалә биргән бит! Шулай итеп, көнчелек - шайтани авыру, адәм баласының җәлегенә үтә. Көнчелек бер аерым кешедә генә түгел, хәтта кабилә, халык, милләт дәрәҗәсенә дә күтәрелә. Күреп торабыз, бүген көнчелек иҗтимагый чиргә, авыруга әйләнеп бара. Малда, акчада, ризыкта берничек тә тигезлек була